Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Каргалы авылы җирлегенең Каргалы авылы торак пунктында
гражданнар җыены

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Каргалы авыл җирлеге составына керүче Каргалы авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре хакында

# КАРАР

2019 елның 15 ноябре № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 25.1, 56 нчы маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасының 35 нче маддәсе нигезендә түбәндәге сорау буенча 2019 елның 15 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлегенең Каргалы авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, балачактан инвалид һәм I төркем инвалидлардан тыш, 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- авыл эчендәге юлларга вак таш салу;

- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, Каргали авылында су белән тәэмин итүнең инженерлык челтәрләрен реконструкцияләүгә проект-смета документациясен эшләү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 1467 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 763 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» тавышы өчен халык җыенында катнашкан 717 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 46 кеше тавыш бирде.

Алда язылганнар нигезендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлегенең Каргалы авылы торак пунктында гражданнар җыенын булды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә дип таныrга.

2. “Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлегенең Каргалы авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, балачактан инвалид һәм I төркем инвалидлардан тыш, 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- авыл эчендәге юлларга вак таш салу;

- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, Каргали авылында су белән тәэмин итүнең инженерлык челтәрләрен реконструкцияләүгә проект-смета документациясен эшләү буенча карар кабул ителде дип санарга.

3. Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлегенең Каргалы авылы территориясендә Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлегенең Каргалы авылы территориясендә яшәү

урыны буенча теркәлгән, балачактан инвалид һәм I төркем инвалидлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- авыл эчендәге юлларга вак таш салу;

- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, Каргали авылында су белән тәэмин итүнең инженерлык челтәрләрен реконструкцияләүгә проект-смета документациясен эшләү.

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм игъланнар такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга кирәк.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Каргалы авыл җирлеге башлыгы ________________ М.А. Заһидуллин